РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«24» декабрь 2024 ел г. Альметьевск № 4147

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы спорт әзерлегенең өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы физкультура спорт учреждениеләренең яшь белгечләренә - хезмәткәрләргә акчалата түләүләр билгеләү турында» 2023 елның 29 ноябрендәге 7146 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Спорт әзерлегенең өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы физкультура спорт учреждениеләренең яшь белгечләренә - хезмәткәрләргә акчалата түләүләр» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 31 октябрендәге 979 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында»Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 7 мартындагы 127 номерлы карары нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы спорт әзерлегенең өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы физкультура спорт учреждениеләренең яшь белгечләренә - хезмәткәрләргә акчалата түләүләр билгеләү турында» 2023 елның 29 ноябрендәге 7146 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 1 пунктындагы өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хуҗалык төзелешенә бер тапкыр бирелә торган 100 000 сум күләмендә акчалата түләү.»;

1.2. 1 нче кушымтаның 1 пунктындагы өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хуҗалык төзелешенә бер тапкыр бирелә торган 100 000 сум күләмендә акчалата түләү.».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

заказ № 1-851

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2024 елның 1 гыйнварында барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары С.В. Лаптевага йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе Г.М. Хәбутдинова